ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Красна торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

8 апрель 2024 ел № 1

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2024 елның 6 апрелендә 18.00 сәгатьтә булган гражданнар җыены нәтиҗәләре белән гражданнар җыены беркетмәсе төзелде, “2024 елда яшәү урыны буенча теркәлгән һәм даими яшәүче һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә ризалыгыгыз бармы ” дигән соравы буенча Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының, Мүлмә авыл җирлеге Красна торак пунктында яшәүче һәм җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне үтәү буенча алынган акчаларны хәл итү өчен түбәндәге эшләргә юнәлдерелде:

а) традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (агачларны кисү, чүп-чар чыгару, территорияне уратып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

«РИЗА» «КАРШЫ»

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 35 (утыз биш) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 19 (унтугыз) кеше, бу 54%ны тәшкил итә.

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 19 (унтугыз) катнашучы тавыш бирде; “Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Красна торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип танырга.

2. 2024 елда үзара салым акчасын, яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Мүлмә авыл җирлеге Красна авылы территориясендәге даими яшәүче һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум (биш йөз) күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

а) традицион җирләү урыннарын ремонтлау, коймалар урнаштыру, төзекләндерү (агачларны кисү, чүп-чар чыгару, территорияне уратып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу)

4. Россия Федерациясе Президентының «Россия Федерациясендә өлешчә мобилизация игълан итү турында» 2022 елның 21 сентябрендәге 647 номерлы Указы нигезендә Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизация һәм контракт буенча хәрби хезмәткә чакырылган Россия Федерациясе гражданнарын һәм аларның гаиләләрен, 1 төркем инвалидларын 2024 елда үзара салым түләүдән тулысынча азат итәргә. Бары тик 1 (бер) кеше. (Исемлек бирелә).

5. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат

рәсми порталында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Л.Р. Зиннәтуллин